**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ДӨБЪЯЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**
422720, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Дөбъяз авылы, Ленин ур., 28

**СОВЕТ ДУБЪЯЗСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422720, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Дубъязы, ул. Ленина, 28

тел./факс 8(84365) 61-2-86, e-mail: Dub.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**18 июль 2022 ел** **№ 52**

**Дөбьяз авыл җирлеге Советының 30.04.2018 елның 84 нче номерлы “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең даими нигезендә үз вәкаләтләрен башкаручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында” карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2022 елның 881нче номерлы «Муниципаль берәмлекләр башлыкларын, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларын, депутатларны, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларын даими нигездә гамәлгә ашыручы айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен арттыру турында" карары нигезендә, Дөбьяз авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге Советы,

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге Советының 30.04.20218 елның 84 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең даими нигезендә үз вәкаләтләрен башкаручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында" карары белән расланган (24.09.2018 № 100, 25.12.2018 № 110, 30.09.2020 № 4 карары редакциясендә)

Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге башлыгының айлык акчалата бүләкләү күләмен 2022 елның 1 октябреннән 1,04 тапкырга арттырырга.

2. 2022 елның 1 октябреннән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге Советының 30.04.20218 елның 84 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең даими нигезендә үз вәкаләтләрен башкаручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында" карары белән расланган (24.09.2018 № 100, 25.12.2018 № 110, 30.09.2020 № 4карары редакциясендә) Дөбьяз авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрлеренең айлык окладларын 1,04 тапкырга арттырыга.

3. Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладлары күләмнәрен исәпләү өчен әлеге карарның 2 пункты нигезендә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфа окладьı күләмен 1,04 тапкыр индексацияләү һәм аны 11958 сум күләмендә билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының, муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә үз вәкаләтләрен башкаручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 30.04.2018 ел, 81 нче карары белән расланган(24.09.2018 № 100, 25.12.2018 № 110, 30.09.2020 № 4 карары редакөиясендә) 2 нче кушымта таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге башлыгының айлык акчалата бүләкләү күләме»

| Вазыйфаның исеме | Акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| | 11 төркем |
| Авыл җирлеге башлыгы | 17943 |

5. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырырга.

6.Әлеге карарны авыл җирлеге мәгълүмат стендларына, http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча Биектау муниципаль районының рәсми сайтына, http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасының рәсми хокукый сайтына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә)

7. Бу карар 2022 елның 1 октябреннән рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Р.Ш.Галиуллин